Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты

28 гыйнвар 2020 ел № 17

«Беренче поселок» I чират микрорайоны
территориясен ызанлау проектын
әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планлаштыру структурасы элементларын билгеләү максатларында,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасының техник инвентаризацияләү бюросы» акционерлык җәмгыятенә инвестиция чаралары хисабына Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре адресы буенча урнашкан «Беренче поселок» I чират микрорайоны территориясен ызанлау проектын эшләүгә керешергә тәкъдим итәргә (1 нче кушымта).

2. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.


4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе Л. Ф. Вәлиев

Әлмәт шәһәр Башкарма
комитетының 2020 елның
«28» гыйнвар № 17 карарына
1 нче кушымта

«Беренче поселок» I чират микрорайоны территориясе чикләре




Башкарма комитет җитәкчесенең
төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косарев